# КАРАР

## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гүлкин авыл җирлеге составына керүче Гүлкин торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

04.12.2021

№ 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 04 нче декабрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Гүлкин авыл җирлегенең Гүлкин авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2022 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- Үзәк урамы буенча 2 данә шлагбаум әзерләү һәм урнаштыру, Яшьләр урамы- 1 данә;
- зират капкаларын алыштыру һәм урнаштыру;
- зират янында 1 данә санда мәгълүмати щит урнаштыру;
-зират коймаларын буяу;
-Бөек Ватан сугышыннан кайтучыларга Мемориаль тактаәзерләү һәм урнаштыр.»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 195 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 101 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 101 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гүлкин авыл җирлегенең Гүлкин торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.
2. «Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Гүлкин авыл җирлегенең Гүлкин авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2022 елда

үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- Үзәк урамы буенча 2 данә шлагбаум әзерләү һәм урнаштыру, Яшьләр урамы-1 данә;
- зират капкаларын алыштыру һәм урнаштыру;
- зират янында 1 данә санда мәгълүмати щит урнаштыру;
-зират коймаларын буяу;
-Бөек Ватан сугышыннан кайтучыларга Мемориаль тактаәзерләү һәм урнаштыр.» - соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гүлкин авыл
җирлеге башлыгы С.Д. Инькова